Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә якынча җаваплар (мәктәп туры, 2017-2018 уку елы). 10 нчы сыйныф

Максималь балл – 45.

I. Теоретик биремнәр. (7 балл)

1. XX йөз башы татар әдәбиятында мөрәҗәгать ителгән реализм иҗат юнәлешенә мөнәсәбәтле ике иҗат агымын аерып билгеләгез һәм исемнәрен язып куегыз. (4 балл)

М**әгърифәтчелек реализмы һәм тәнкыйди реализм.**

2. Түбәндә аталган әсәрләрнең кайсылары XX йөз башы татар әдәбиятына карый. (3 балл)

А) “Хисаметдин менла”

Б) **“Китмибез!”**

В) **“Акчарлаклар”**

Г) “Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә”

Д) **“Яшь йөрәкләр”**

II. Әдәби әсәргә кагылышлы биремнәр. (23 балл)

1. Ф.Әмирханның “Хәят” повестенда геройларның эш-гамәлләре аша нинди сыйфатлар хуплана, ниндиләре тәнкыйтьләнә, кире кагыла? Аерып куеп, санап чыгыгыз. (10 балл)

Х**уплана – яңача яшәргә омтылыш, күңел кушканча яшәргә тырышу, әхлаклылык, мәдәни яктан алга китеш һ.б., тәнкыйтьләнә – иске гадәтләргә ябышып ятарга тырышу, язмышка гына буйсыну, үз тормышыңны үзгәртү өчен гамәлләр кылмау һ.б.**

2. Ф.Әмирханның “Хәят” повестенда җиткерелгән төп идеяне ачыклап языгыз, укучыга нинди фикер әйтелә? (5 балл)

3. Ф.Әмирханның “Хәят” повестенда Хәят образын сурәтләү барышында кулланылган әдәби алымнарны билгеләп языгыз. (8 балл)

Портрет, психологик анализ һ.б.

II. Иҗади эш. (15 балл)

Төрле тел-сурәтләү чараларын кулланып, үзегез теләгән бер предметны детальләп сурәтләп языгыз.